# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Мамадыш муниципаль районы Тауиле авыл җирлеге составына керүче Чаксы торак пунктында үзарасалым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

№ 6 30 октябрь, 2024 ел

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 нче статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35 нче статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Тауиле авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставының 23 статьясы, Мамадыш муниципаль районы Тауиле авыл җирлегенең Чаксы торак пунктында 2024 елның 30 октябрендә узган үзарасалым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

1. « Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Тавель авыл җирлегенең Чаксы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 һәм 2 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннарыннан, күпбалалы гаиләләрдән, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан тыш, 2025 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертергә. свода катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын, Россия армиясе сафларына срочная хезмәткә чакырылган гражданнарны һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү:
   - торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Чаксы торак пунктында юлларны грейдерлау һәм кардан чистарту ,эшләр өчен шартнамә буенча түләү)
   - урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү , электр энергиясен тапшыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (Чаксы торак пунктында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, махсус җайланма лампаларын сатып алу һәм урнаштыру, эш өчен килешү буенча түләү).
   - торак пункт территориясен төзекләндерү ( Чаксы торак пунктында ял итү һәм башка культуралы чаралар үткәрү өчен ял мәйданчыгы урнаштыру ,материаллар сатып алу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү)

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 91 кеше кертелгән;
гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны: 64 кеше, 70,3 % тәшкил итә:
Гражданнар җыенында катнашучыларның ачык тавыш бирү нәтиҗәләре түбәндәгечә бүленде:
«ЗА» позициясе өчен 62 граждан тавыш бирде;
«КАРШЫ»позициясе өчен 2 граждан тавыш бирде;

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1.Гражданнарның үзарасалым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Мамадыш муниципаль районы Тауиле авыл җирлегенең Чаксы торак пунктында узган гражданнар җыенын - уздырылган, нәтиҗәләре - дөрес, дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Тавель авыл җирлегенең Чаксы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 һәм 2 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннарыннан, күпбалалы гаиләләрдән, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан тыш, 2025 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертергә. свода катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын, Россия армиясе сафларына срочная хезмәткә чакырылган гражданнарны һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Чаксы торак пунктында юлларны грейдерлау һәм кардан чистарту ,эшләр өчен шартнамә буенча түләү)
- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү , электр энергиясен тапшыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (Чаксы торак пунктында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, махсус җайланма лампаларын сатып алу һәм урнаштыру, эш өчен килешү буенча түләү).
- торак пункт территориясен төзекләндерү ( Чаксы торак пунктында ял итү һәм башка культуралы чаралар үткәрү өчен ял мәйданчыгы урнаштыру ,материаллар сатып алу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү)

3. Әлеге карарны Тауиле  авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Тауиле  авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Мамадыш муниципаль районы
Тауиле  авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе В.И.Иванов